“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында

БОЕРЫК

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында”гы 79нчы Федераль закон, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2015 елның 10 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазифаларын биләгән затлар тарафыннан, чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү хакындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 506нчы Указы, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2016 елның 12 гыйнварында кабул ителгән “Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларын биләгән затлар тарафыннан (аларны бу вазифаларга Татарстан Республикасы Президенты билгели һәм азат итә), чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү хакындагы Нигезләмәне раслау турында”гы УП-5нче Указы нигезендә, фәрман бирәм:

1. “Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының (алга таба – Агентлык) дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәне (1нче кушымта) расларга.

2. Кадрлар бүлегенә (Э. М. Исмәгыйлева) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгән вакыттан алып 3 (өч) эш көне дәвамында, Агентлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

3 Элеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче А.Р.Зарипов

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан 2016 елның 24 февралендә кабул ителгән 7-п боерыгы нигезендә расланды

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый, дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында

Нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә белән “Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык җитәкчесе) рөхсәте белән “Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре) тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый, дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен (алга таба шулай ук – исемнәр, бүләкләр) кабул итү тәртибе раслана.

2. Гражданлык хезмәткәре үзенә мактаулы исемнәр, бүләкләр тапшырылган вакытта Агентлык җитәкчесеннән рөхсәт алырга тиеш.

3. Исем, бүләк алучы яки чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый, дини берләшмәләр тарафыннан бүләк алачагы турында хәбәр җиткерелгән дәүләт хезмәткәре, өч эш көне дәвамында Агентлыкның кадрлар бүлегенә Агентлык җитәкчесе исеменә, әлеге Нигезләмәгә 1нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән чит ил, халыкара оешма, сәяси партия һәм башка иҗтимагый, дини берләшмәнең (алга таба – гариза) мактаулы һәм махсус исемен кабул итәргә рөхсәт итү турында гариза бирә. Гаризаны карау вакыты 10 эш көнен тәшкил итә.

4. Мактаулы исем, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар бүлегенә Агентлык җитәкчесе исеменә, Нигезләмәгә 2нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән чит ил, халыкара оешма, сәяси партия һәм башка иҗтимагый, дини берләшмәнең (алга таба – белдерү кәгазе) мактаулы һәм махсус исемен алудан баш тарту турында белдерү кәгазе бирә.

5. Мактаулы исем, бүләкне Агентлык җитәкчесенең гаризаны карау нәтиҗәләре буенча тиешле карар кабул иткәнчегә кадәр алган гражданлык хезмәткәре мактаулы исем, бүләк документларының һәм аларның

документларының төп нөсхәләрен аларны алган вакыттан алып өч эш көне дәвамында Агентлыкның кадрлар бүлегенә саклауга тапшыра.

6. Гражданлык хезмәткәре мактаулы исем, бүләкне хезмәт командировкасы вакытында алган яки алардан баш тарткан очракта, гариза яки белдерү кәгазен тапшыру срогы гражданлык хезмәткәренең командировкадан әйләнеп кайткан көненнән алып исәпләнә.

7. Үзенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында Нигезләмәнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытка гариза яки белдерү кәгазен, мактаулы исем, бүләк документларының һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра алмаган очракта, гражданлык хезмәткәре гариза яки белдерү кәгазен, мактаулы исем, бүләк документларының һәм аларның документларының төп нөсхәләрен әлеге сәбәпне юкка чыгарганнан соң алдагы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Гариза (белдерү кәгазе) кадрлар бүлеге тарафыннан әлеге Нигезләмәгә 4нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән регистрация журналында килгән көнне теркәлә. Теркәлгән гаризаны (белдерү кәгазен) кадрлар бүлеге ике эш көне дәвамында Агентлык җитәкчесе каравына тапшыра.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә гаризаны тикшерү нәтиҗәләре буенча Агентлык җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карар хакында хәбәр итә һәм аңа җитәкченең резолюциясе белән кадрлар бүлегенең мөһере басылган гаризаның (белдерү кәгазенең) күчермәсен тапшыра. Гаризаның (белдерү кәгазенең) төп нөсхәсе җитәкченең резолюциясе белән гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

10. Агентлык җитәкчесе гражданлык хезмәткәренең Нигезләмәнең 5нче пунктында күрсәтелгән гаризасын канәгатьләндергән очракта, Агентлыкның кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында гражданлык хезмәткәренә мактаулы исем, бүләк документларының һәм аларның документларының төп нөсхәләрен тапшыра. Шуның белән бергә, Нигезләмәнең 3нче кушымтасы нигезендә кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Агентлык җитәкчесе гражданлык хезмәткәренең Нигезләмәнең 5нче пунктында күрсәтелгән гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, Агентлыкның кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында мактаулы исем, бүләк документларының һәм аларның документларының төп нөсхәләрен чит ил, халыкара оешма, сәяси партия һәм башка иҗтимагый һәм дини берләшмәнең тиешле органына тапшыра.

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә

1нче кушымта

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе

___________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

___________________________________

(кемнән: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, биләгән вазифасы)

Чит ил, халыкара оешма, сәяси партия һәм башка иҗтимагый һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген кабул итәргә рөхсәт итү турында

гариза

_____________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

_____________________________________________________________________

(нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан тапшырылган (тапшырылачак), нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән (бүләкләнәчәк)

_____________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар тапшыру көне һәм урыны)

кабул итәргә рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Мактаулы яки махсус исем һәм аның документлары, бүләк һәм аның документлары, орден-медальләр һәм аларның документлары (кирәклесенең астына сызарга) ____________________________________________

(мактаулы яки махсус исем, бүләкнең атамасы)

_____________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исем, бүләк яисә башка орден-медальләрнең документлары атамалары)

№___ кабул итү-тапшыру акты буенча «___»____________20__ел “Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының кадрлар бүлегенә тапшырылган.

“___”________________20___ел _______________ ____________________

(имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә

2нче кушымта

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе

____________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

____________________________________
(кемнән: фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, биләгән вазифасы)

Чит ил, халыкара оешма, сәяси партия һәм башка иҗтимагый һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында

белдерү

Түбәндәге бүләкләрне алудан баш тартуым хакында белдерәм
________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

________________________________________________________________________
(нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан тапшырылган, нинди казанышлар өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән

“___”_________________20___ел ________________ ____________________
(имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә

3нче кушымта

кабул итү-тапшыру
АКТы

«__»______________20__ел №___________

Без, имза куючылар (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы) ______________________________________________________________________ түбәндәгеләрне

| № п/п | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |

тапшыру/кабул итеп алу (тиешлесенең астына сызарга), ә Агентлыкның кадрлар бүлеге (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) ______________________________________________________________________ тапшыру/кабул итеп алуы (тиешлесенең астына сызарга) турында акт төзедек.

Тапшырды

Тапшырды Кабул итте

___________________________ ___________________________
(имза, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) (имза, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

“Татмедиа” Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит илләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә

4нче кушымта

Гариза (белдерүләрне) исәпкә алу журналы

| № | Гариза биргән гражданлык хезмәткәренең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме | Гариза биргән гражданлык хезмәткәренең вазифасы | Гаризаның кергән көне | Бүләк, исемнең атамасы | Кабул итү-тапшыру актының реквизитлары (әгәр булса) | Гаризаны кабул итеп алган затның имзасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Гариза биргән затның имзасы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Агенлык җитәкчесенең карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |